**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАР**

№1 24.02.2015 ел

**2015 елга Аксубай муниципаль районы**

**Савруш авыл җирлеге территориясендә**

**наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

«2020 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясен раслау турында» 09.06.2010 ел, № 690 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, наркомания таралу куркынычын киметү максатларында, «наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» Россия Федерациясе Президентының 18.10.2007 ел, № 1374 Указына таянып, 2015 елга чаралар планнары, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотик чараларны куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Савруш авыл җирлегенең 2015 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Савруш авыл җирлеге

Башлыгы: А.Г.Кузьмин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САВРУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

кушымта №1
Савруш авыл җирлеге
башлыгы карарына

**Составы**

**Татарстан Республикасы**

**Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Башкарма комитет каршындагы наркотикларга каршы комиссия**

Комиссия рәисе: Кузьмин Андрей Георгиевич Савруш авыл җирлеге башлыгы

Комиссия секретаре: Васильева Надежда Николаевна,

Савруш Башкарма комитеты җитәкчесе

авыл җирлеге башлыгы урынбасары

Комиссия әгъзалары: Хөснетдинов Руслан Гомәр улы,

Аксубай районы буенча Россия ЭЭМ МБ участок инспекторы

Герасимова Ирина Алексеевна, Иске Савруш төп мәктәбе директор

Федорова Мария Михайловна,

Иске Савруш фельдшер-акушерлык пункты
мөдире

кушымта2
Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
№ 1 24.02.2015 ел

**План**

**2015 елга Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге территориясендә**

**наркотикларга каршы чаралар**

Программаның төп чаралары булып тора:

- оештыру чаралары;

- наркоманияне профилактикалау системасы учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеге;

- наркотик һәм психотроп матдәләр куллануның тискәре нәтиҗәләрен профилактикалау;

- наркоманиягә каршы тору системасы учреждениеләренең матди-техник базасын камилләштерү;

- эшчәнлекне мәгълүмат белән тәэмин итү

| **№п/п** | **эчтәлек** | **башкаручы** | **Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|---|
| 1 | Наркотикларга каршы комиссия утырышларын уздыру | Наркотикларга каршы комиссия | Кварталга 1 тапкыр |
| 2 | Наркоманияне һәм наркоҗинаятьчелекне профилактикалау өлкәсендәге законнарны камилләштерү буенча норматив-хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу | Наркотикларга каршы комиссия | Кирәк булганда |
| 3 | Мәдәни-массакүләм һәм ял итү яшьләр чараларын уздыру урыннарында наркотикларның таралу фактлары турында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү һәм анализлау. | Наркотикларга каршы комиссия | Даими |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Наркоманиягә каршы торуның агымдагы мәсьәләләрен, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән мәгълүматны яктырту өчен ММЧ вәкилләре белән хезмәттәшлек. | Киңәш | Кирәк булганда |
| 5 | Китапханәләр, мәгариф учреждениеләре базасында наркомания, алкоголизм һәм ВИЧ-инфекция проблемалары буенча мәгълүмат банкын булдыру һәм саклау. | Наркотикларга каршы комиссия | Даими |
| 6 | Тар профильле белгечләрне җәлеп итеп, авыр тормыш хәленә эләккән яшүсмерләргә консультацияләр үткәрү (психолог, нарколог, юрист һ. б.) | АНК, мәктәп | Кирәк булганда |
| 7 | Авыр тормыш хәлендә калган балаларны ачыклау, балигъ булмаганнар белән рәхимсез мөгамәлә фактларын булдырмау, имин булмаган гаиләләрне ачыклау, балигъ булмаганнарны җинаятьләргә тарту фактларын ачыклау һәм булдырмау буенча рейдларны даими уздыру. | АНК | Ай саен |
| 8 | Балаларны тәрбияләүдә һәм урнаштыруда практик ярдәм күрсәтү өчен имин булмаган гаиләләргә һәм социаль куркыныч янаган гаиләләргә бару. | АНК | Айлап |
| 9 | Яшүсмерләрнең тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр, наркомания, ВИЧка зыянлы йогынтысы турында мәгълүматлы булуына Мониторинг. | Мәктәп, китапханә | Даими |
| 10 | Наркоманияне профилактикалау буенча авыл китапханәсендә чаралар үткәрү (мәгълүмат стендлары, укучылар конференцияләре). | Китапханә | Ноябрь |
| 11 | Наркоманияне һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча айлык үткәрү | Авыл җирлеге башкарма комитеты, АНК, мәктәп | Октябрь |
| 12 | "Музыка-әйе! Наркотикларга-юк!", "Наркотикларсыз дөнья", «СПИД йокламый»акциясе-протесты | Мәдәният йорты, мәктәп | Апрель-Декабрь |
| 13 | Наркотиклы үсемлекләрне юк итү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ ЭЭМ УУП Аксубай районы участок уполномоченные | Май-октябрь |
| 14 | Алкогольле продукция һәм сыра сату белән шөгыльләнүче сәүдә нокталары буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ ЭЭМ Аксубай районы ӨУП (полиция) | Айлап |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | Кичке вакытта дискотекаларны, яшьләр массакүләм чараларын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | АНК, РФ ЭЭМ Аксубай районы ӨУП (полиция) | Айлап |
| 16 | АНКның 2016 елга эш планын раслау. | АНК | Декабрь 2015г |